ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Транспорт салымы турында” Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Транспорт салымы турында” 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“4. Әлеге Законның 5 статьясында каралган салым ставкаларыннан 50 процент күләмендә ташлама түбәндәгеләргә карата билгеләнә:

1) Россия Федерациясендә җитештерелгән һәм кимендә ЕВРО-2 экологик нормаларына туры килә торган двигательләр белән җиһазландырылган, лизинг бирүче балансында тора торган һәм лизингка кимендә бер елга тапшырылган, двигателенең куәте 150 ат көченнән югарырак булган йөк автомобильләренә, автобусларга;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыручы һәм гаскәр тибындагы автомобиль колонналарын төзүгә һәм тотуга мобилизацион йөкләмәләр бирелгән оешмалар милкендә булган гаскәр тибындагы автомобиль колоннасы составына кертелгән автобусларга. Ташлама транспорт чаралары гаскәр тибындагы автомобиль колоннасы составында булган чорга бирелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

Казан,Кремль
2016 ел, 26 декабрь
№ 103-ТРЗ